СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

12 ноябрь 2020 ел

№ 12

«Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының “Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 2016 елның 3 октябрендәге 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының “Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 2016 елның 3 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**10.1.3 пуктның 4 подпунктын** «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң:

«һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр» сүзләре белән тулыландырырга;

**20.1 пунктның 4 подпунктын** түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга:

«(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәтне узган чор өчен хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру».

2. Әлеге карарны Зеленая Роща авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында “Авыл җирлекләре” бүлегендә (leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Зеленая Роща авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлы